**«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«24» 12 2024 ел** **№ 1327**

Чистай муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының
2021 елның 29 сентябрендәге 1099 номерлы
боерыгы белән расланган муниципаль милектәге
җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә,
арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга,
түләүсез файдалануга бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының 29.09.2021 ел, №1099 боерыгы белән расланган торглар үткәрмичә, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-3.3.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространстволы мәгълүматлардан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»

-3.4.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән мизгелдән файдаланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространстволы мәгълүматлардан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»

-3.5.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.6. Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда башкарыла.

Регламентның 3.5.3 - 3.5.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалануга рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 14 эш көне, җир кишәрлеге биреләчәк дигән хәбәр басылып чыккан очракта – 47 эш көне.»

-3.6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:
дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документларын һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару барышында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә һәм Палатада яисә КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген

тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслаучы документны имзалаган көннән алып бер эш көне эчендә Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты (Палата) тарафыннан башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат системаларында белешмәләрне урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора.»

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Ю. Исхакова